МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.03.2023 Казан ш. № 02-23

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 19.11.2021 ел, № 02-115 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына караган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турында күрсәтмәләргә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 19.11.2021 ел, № 02-115 боерыгы (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 11.07.2022 № 02-88, 02.11.2022 № 02-132, 09.12.2022 № 02-145, 29.12.2022 № 02-153 нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына караган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турында күрсәтмәләргә үзгәрешләрне (кушымта итеп бирелә) расларга.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
« 27 » 03.2023 ел
№ 02-23 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 19.11.2021 ел, № 02-115 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына караган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турында күрсәтмәләргә кертелә торган үзгәрешләр

1. «Гомуми нигезләмәләр» 1 пунктының егерме сигезенче абзацында «Россия Федерациясе бюджет классификациясе кодларын булдыру һәм куллану тәртибе, аларның структурасы һәм билгеләнеше принциплары турында» 6 июнь, 2019 ел, № 85н» дигән сүзләрне «Россия Федерациясе бюджет классификациясе кодларын булдыру һәм куллану тәртибе, аларның структурасы һәм билгеләнеше принциплары турында» 24 май 2022 ел № 82н» дигән сүзләргә алыштырырга.

2. «Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды чыгымнары исемлеге һәм аларны тиешле максатчан статьяларга кертү» 2 пунктында:

а) «2025 елга кадәр Татарстан Республикасында сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү» дәүләт программасы» 2.1. пунктчасында «01 2 10 00000 Югары технологияле медицина ярдәмен камилләштерү, дәвалауның нәтиҗәле яңа ысулларын үстерү» максатчан статьясында «- 54030 Федераль бюджет средстволары хисабына, сөяк җелеге һәм (яки) гемопоэтик төп күзәнәкләр донорының сөяк җелеге һәм (яки) гемопоэтик төп күзәнәкләрне алу урынына барып кайту чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү» чыгымнар юнәлешенең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Сөяк җелеге һәм (яки) гемопоэтик төп күзәнәкләр донорының сөяк җелеге һәм (яки) гемопоэтик төп күзәнәкләрне алу урынына барып кайту чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү максатыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 45403 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

б) «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында мәгариф һәм фәнне үстерү» дәүләт программасы» 2.2. пунктчасында:

«02 2 Е1 00000 «Заманча мәктәп» Федераль проекты» максатчан статьясында «- 51720 Гомуми белем бирү оешмаларын, шул исәптән адаптацияләнгән төп гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыручы гомуми белем бирү оешмаларын җиһазлар белән тәэмин итүгә (матди-техник базасын яңартуга), укыту һәм тәрбия өчен средстволар белән тәэмин итүгә финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешенең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Гомуми белем бирү оешмаларын, шул исәптән адаптацияләнгән төп гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыручы гомуми белем бирү оешмаларын җиһазлар белән тәэмин итүгә (матди-техник базасын яңартуга), укыту һәм тәрбия өчен средстволар белән тәэмин итүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25172 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

«02 2 Е4 00000 «Цифрлы мәгариф мохите» Федераль проекты» максатчан статьясында «- 52130 Цифрлы мәгариф мохитен кертү һәм укучыларның цифрлы күнекмәләрен үстерү өчен мәгариф оешмаларының матди-техник базасын яңартуга финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешенең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Цифрлы мәгариф мохитен кертү һәм укучыларның цифрлы күнекмәләрен үстерү өчен мәгариф оешмаларының матди-техник базасын яңартуга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25213 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

«02 2 ЕВ 00000 «Россия Федерациясе гражданнарын ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү» федераль проекты» максатчан статьясында «- 51790 Гомуми белем бирү оешмаларында директорның тәрбия һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән берлектә эшләү буенча киңәшчеләре эшчәнлеген тәэмин итү буенча чаралар үткәрүгә финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешенең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Гомуми белем бирү оешмаларында директорның тәрбия һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән берлектә эшләү буенча киңәшчеләре эшчәнлеген тәэмин итү буенча чаралар үткәрүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25179 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

«02 4 03 00000 Һөнәри белем бирү системасын модернизацияләү, мәгариф өлкәсендә чаралар үткәрү» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- R1770 Алга китешле һөнәри әзерлек үзәкләрен булдыруга һәм аларның эшләвен тәэмин итүгә финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча алга китешле һөнәри әзерлек үзәкләрен булдыруга һәм аларның эшләвен тәэмин итүгә федераль бюджеттан субсидияләр һәм

Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Алга китешле һөнәри әзерлек үзәкләрен булдыруга һәм аларның эшләвен тәэмин итүгә бюджетларга субсидияләр» 000 2 02 25177 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.»;

«02 4 Е6 00000 «Яшь профессионаллар (Һөнәри белем өлкәсендә көндәшлеккә сәләтне арттыру)»федераль проекты» максатчан статьясында «- 51770 Алга китешле һөнәри әзерлек үзәкләрен булдыруга һәм аларның эшләвен тәэмин итүгәфинаслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешен төшереп калдырырга:

в) «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасы» 2.3. пунктчасында:

«03 1 01 00000 Федераль һәм республика законнарында билгеләнгән гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм чараларын күрсәтү» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- 94010 «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе средстволары хисабына, даими яшәү урыныннан китәргә һәм ашыгыч тәртиптә күпләп даими яшәү урынына башка территорияләргә күченгән Херсон шәһәрендә һәм Херсон өлкәсенең бер өлешендә яшәгән кешеләргә мөлкәт сатып алуга бер тапкыр түләү бирү чыгымнары

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе средстволары хисабына, даими яшәү урыныннан китәргә һәм ашыгыч тәртиптә күпләп даими яшәү урынына башка территорияләргә күченгән Херсон шәһәрендә һәм Херсон өлкәсенең бер өлешендә яшәгән кешеләргә мөлкәт сатып алуга бер тапкыр түләү бирүгә хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга средстволарның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына дәүләт (муниципаль) оешмаларыннан кире кайтарылмый торган башка керемнәр» 000 2 03 02099 02 0000 150 керемнәзр төре коды буенча чагылдырыла.»;

«03 5 01 00000 Гаиләләргә социаль ярдәм чараларын үстерү» максатчан статьясында «- 31440 Сигез яшьтән унижиде яшькә кадәрге балага түләүләрне хәл итүгә Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетына субвенцияләр» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 31440 Сигез яшьтән унижиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләүне хәл итүгә Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды бюджетына субвенцияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Балалы гаиләләргә айлык акчалата түләү турында» 31 март, 2022 ел, № 175 Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, сигез яшьтән унижиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләүне хәл итүгә Россия

Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды бюджетына субвенцияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субвенцияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Сигез яшьтән униҗиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләүне хәл итүгә Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды бюджетына субвенцияләр» 000 2 02 33144 06 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

«- 31460 Унҗиде яшькә кадәрге балалары булган аз керемле гаиләләргә һәм йөкле хатын-кызларга айлык универсаль пособие түләүгә финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 31460 Бала тудыру һәм тәрбияләүгә бәйле айлык пособие түләүгә Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды бюджетына субвенцияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча бала тудыру һәм тәрбияләүгә бәйле айлык пособие түләүгә Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды бюджетына субвенцияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субвенцияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Бала тудыру һәм тәрбияләүгә бәйле айлык пособие түләүгә Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды бюджетына субвенцияләр» 000 2 02 33146 06 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

г) «Татарстан Республикасында яшәүчеләрне сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасы» 2.4. пунктчасында:

«04 4 F3 00000 «Яшәү өчен яраксыз торак фондын тотрыклы кыскартуны тәэмин итү» фекдераль проекты» максатчан статьясында «- 67483 Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм итү фонды средстволары хисабына, «Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проектының «Яшәү өчен яраксыз торак фондын тотрыклы кыскартуны тәэмин итү» федераль проектын тормышка ашыру кысаларында 2019 – 2023 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча Республика адреслы программасы чараларын тәэмин итү» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 67483 Территорияләрне үстерү фонды средстволары хисабына, «Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проектының «Яшәү өчен яраксыз торак фондын тотрыклы кыскартуны тәэмин итү» федераль проектын тормышка ашыру кысаларында 2019 – 2023 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча Республика адреслы программасы чараларын тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проектының «Яшәү өчен яраксыз торак фондын тотрыклы кыскартуны тәэмин итү» федераль проектын тормышка ашыру кысаларында 2019 – 2023 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча Республика адреслы программасы чараларын тәэмин итүгә «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга средстволарның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү, шул исәптән аз катлы торак төзелешен үстерү зарурилыгыннан чыгып, гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча чараларны тәэмин итүгә «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясеннән Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына кире кайтарылмый торган керемнәр» 000 2 03 02040 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

«04 К 00 00000 «Татарстан Республикасында яшәүчеләрне сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» кече программасы» максатчан статьясында:

түбәндәге чыгымнар юнәлешләрен өстәргә:

«- 03610 «Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәге өчен инженерлык һәм юл инфраструктурасы объектларын төзү» объектын булдыру

- 03611 «ВЭБ.РФ» үсеш дәүләт корпорациясе средстволары хисабына, «Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәге өчен инженерлык һәм юл инфраструктурасы объектларын төзү» объектын булдыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәге өчен инженерлык һәм юл инфраструктурасы объектларын төзү» объектын булдыруга «ВЭБ.РФ» үсеш дәүләт корпорациясе средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга средстволарның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына дәүләт (муниципаль) оешмаларыннан кире кайтарылмый торган башка керемнәр» 000 2 03 02099 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

- 03612 Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына, «Свияжск мультимодаль логистика үзәге өчен инженерлык һәм юл инфраструктурасы объектларын төзү» объектын булдыру

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Свияжск мультимодаль логистика үзәге өчен инженерлык һәм юл инфраструктурасы объектларын төзү» объектын булдыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.».»;

«- 72360 «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциясез оешмасына торак төзелеше буенча устав эшчәнлеген тормышка ашыруга субсидияләр» чыгымнар юнәлешен төшереп калдырырга;

д) «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында мәдәниятне үстерү» дәүләт программасы» 2.8. пунктчасында:

атамасында «2014 – 2025 елларга» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

беренче абзацында «2014 – 2025 елларга» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

«08 0 00 00000 «Татарстан Республикасында мәдәниятне үстерү» дәүләт программасы» максатчан статьясының беренче абзацында «2014 – 2025 елларга» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

«08 2 А1 00000 «Мәдәни мохит» федераль проекты» максатчан статьясында «- 55840 Төбәк һәм муниципаль театрларны җиһазлауга финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешенең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге максатларга субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Төбәк һәм муниципаль театрларны җиһазлауга бюджетларга субсидияләр» 000 2 02 25584 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.»;

«08 К А1 00000 «Мәдәни мохит» федераль проекты» максатчан статьясында «- 55800 Төбәк һәм муниципаль театрларны реконструкцияләүгә һәм капиталь ремонтлауга финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешенең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге максатларга субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Төбәк һәм муниципаль театрларны реконструкцияләүгә һәм капиталь ремонтлауга бюджетларга субсидияләр» 000 2 02 25580 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.»;

е) «Татарстан Республикасында әйләнә-тирә мохитне саклау, табигать байлыкларын яңарту һәм алардан файдалану» дәүләт программасы» 2.9. пунктчасында «09 2 G6 00000 «Иделне савыктыру» федераль проекты» максатчан статьясында»:

беренче абзацта «түбәндәге юнәлешкә» дигән сүзләрне «түбәндәге юнәлешләргә» дигән сүзләргә алыштырырга;

түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- 19230 Төбәк проекты нәтиҗәсенә ирешү өчен, Идел елгасына куркыныч белән янаучы әйләнә-тирә мохиткә тупланма зыян объектларын юкка чыгару (рекультивацияләү)»;

ж) «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында транспорт системасын үстерү» дәүләт программасы» 2.13. пунктчасында:

«13 6 01 00000 Гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын үстерү» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- 07690 Дәүләти-хосусый партнерлык механизмын куллану нигезендә тормышка ашырылучы проектлар буенча юл эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү»;

«13 6 R1 00000 «Төбәк һәм юл хуҗалыгы челтәре» федераль проекты» максатчан статьясында «- 53892 Юл хуҗалыгы инфраструктурасын үстерүгә финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Юл хуҗалыгы инфраструктурасын үстерү кысаларында дәүләт (муниципаль) милкендәге объектларга капитал салуларны финанслашуга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 27389 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

з) «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы» 2.14. пунктчасында «14 1 06 00000 Үсемлекчелек объектларын төзүгә дәүләт ярдәме» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- 63410 Яшелчә саклагычлар, җиләк-җимеш саклагычлар һәм бәрәңге саклагычлар төзү (реконструкцияләү) эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә субсидияләр»;

и) «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында дәүләт илкүләм сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасы» 2.19. пунктчасында:

атамасында «2014 – 2025 елларга» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

беренче абзацта «2014 – 2025 елларга» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

«20 0 00 00000 «Татарстан Республикасында дәүләт илкүләм сәясәтен тормышка ашыру» максатчан статьясының беренче абзацында «2014 – 2025 елларга» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

«20 0 01 00000 Татарстан Республикасында дәүләт илкүләм сәясәтен тормышка ашыру, Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләрен цивилизацияле үстерү, этникара һәм конфессиара тынычлык һәм татулыкны саклау, гомумроссия гражданлык тәңгәллеген ныгыту, мигрантларны уңышлы төстә социомәдәни адаптацияләү һәм интеграцияләү» максатчан статьясында «- R5180»Дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» Россия Федерациясе дәүләт программасы күрсәткечләренә ирешүгә бердәм субсидия кысаларында финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешенең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» Россия Федерациясе дәүләт программасы күрсәткечләренә ирешүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25518 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

к) «Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» 2.25. пунктчасында:

«26 0 J1 00000 «Туристлык инфраструктурасын үстерү» федераль проекты» максатчан статьясында «- 53320 Туристлык инфраструктурасын үстерүгә юнәлдерелгән иҗтимагый инициативаларны тормышка ашыруны ярдәм итүне тәэмин

итүгә финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 53320 Туристлык инфраструктурасын үстерүгә юнәлдерелгән иҗтимагый инициативаларны тормышка ашыруга ярдәм итүне тәэмин итү»;

«26 0 J2 00000 «Туристлык продуктларыннан файдалану мөмкинлекләрен арттыру» федераль проекты» максатчан статьясында «- 53300 Вакыйгаи чараларга ярдәм итү һәм этәргеч бирү программасын булдыру һәм гамәлгә кертүгә финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешенең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 53300 Вакыйгаи чараларга ярдәм итү һәм этәргеч бирү программасын булдыру һәм гамәлгә кертү»;

«26 К J1 00000 «Туристлык инфраструктурасын үстерү» федераль проекты» максатчан статьясында:

беренче абзацында «түбәндәге юнәлешкә» дигән сүзләрне «түбәндәге юнәлеәләргә» дигән сүзләргә алыштырырга;

түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- 53330 Шәһәр үзәгенең туристлык кодын проектлау буенча төбәк программаларына дәүләт ярдәме

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча шәһәр үзәгенең туристлык кодын проектлау буенча төбәк программаларына дәүләт ярдәменә федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Шәһәр үзәгенең туристлык кодын проектлау буенча төбәк программаларына дәүләт ярдәменә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25333 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла..»;

л) «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасы» 2.32. пунктчасында «37 1 Р5 00000 «Спорт – тормыш нормасы» федераль проекты» максатчан статьясында «- 52290 Спортка әзерләү оешмаларын нормативта каралган халәткә туры китерү өчен спорт җиһазларын һәм кирәк-ярагын сатып алуга финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 52290 Үз атамасында «олимпия» яки шуның нигезендә ясалган сүздән яки сүзтезмәдән файдаланучы, «спорт мәктәбе» дигән махсус атамалы өстәмә белем бирү лешмаларын нормативта каралган халәткә китерү өчен спорт җиһазларын һәм кирәк-ярагын сатып алуга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча үз атамасында «олимпия» яки шуның нигезендә ясалган сүздән яки сүзтезмәдән файдаланучы, «спорт мәктәбе» дигән махсус атамалы өстәмә белем бирү оешмаларын нормативта каралган халәткә китерү өчен спорт җиһазларын һәм кирәк-ярагын сатып алуга федераль бюджеттан

субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабыфна хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Үз атамасында «олимпия» яки шуның нигезендә ясалган сүздән яки сүзтезмәдән файдаланучы, «спорт мәктәбе» дигән махсус атамалы өстәмә белем бирү оешмаларын нормативта каралган халәткә китерү өчен спорт җиһазларын һәм кирәк-ярагын сатып алуга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25229 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.»;

м) «Татарстан Республикасында электр автомобиль транспорты өчен зарядка инфраструктурасын үстерү» дәүләт программасы» 2.34[1] пунктчасында «40 0 01 00000 Татарстан Республикасында электр транспорты средстволары өчен зарядка инфраструктурасы объектларын урнаштыру» максатчан статьясында «- 57660 Федераль бюджет средстволары хисабына, электромобильләр өчен зарядка инфраструктурасын үстерү буенча чараларны тормышка ашыру» чыгымнар юнәлешенең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге максатларга башка бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Электромобильләр өчен зарядка инфраструктурасын үстерү буенча чараларны тормышка ашыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 45766 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

н) «Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының һәм Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фондларының программаларга кертелмәгән юнәлешләре» 2.35. пунктчасында:

«51 0 00 00000 Татарстан Республикасы Президентының Эшләр идарәсен тотуга чыгымнар» максатчан статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«51 0 00 00000 Татарстан Республикасы Рәисенең
Эшләр идарәсен тотуга чыгымнар

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның түбәндәге юнәлешләре буенча Татарстан Республикасы Рәисенең Эшләр идарәсен тотуга һәм эшчәнлеген тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла:

- 02040 Үзәк аппарат

- 02950 Оешмалар милкенә салым һәм җиргә салым түләү
- 92350 Башка түләүләр»;

«99 0 00 00000 Чыгымнарның программаларга кертелмәгән юнәлешләре» максатчан статьясында:

түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- 94020 Даими яшәү урыныннан китәргә мәҗбүр булган һәм ашыгыч тәртиптә күпләп даими яшәү урынына башка территорияләргә күченгән Херсон шәһәрендә һәм Херсон өлкәсенең бер өлешендә яшәгән кешеләргә гражданинның социаль түләүгә хокукын раслаучы дәүләт торак сертификатлары нигезендә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү өчен Территорияләрне үстерү фондыннан алынган средстволар хисабына хәл ителә торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча даими яшәү урыныннан китәргә мәҗбүр булган һәм ашыгыч тәртиптә күпләп даими яшәү урынына башка территорияләргә күченгән Херсон шәһәрендә һәм Херсон өлкәсенең бер өлешендә яшәгән кешеләргә гражданинның социаль түләүгә хокукын раслаучы дәүләт торак сертификатлары нигезендә торак сатып алуга «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясеннән алынучы средстволар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга средстволарның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына дәүләт (муниципаль) оешмаларыннан кире кайтарылмый торган башка керемнәр» 000 2 03 02099 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

«- 09500 Коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү проектын тормышка ашыруга Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм итү фондыннан алынган средстволар хисабына хәл ителә торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 09500 Коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү проектын тормышка ашыруга Территорияләрне үстерү фондыннан алынган средстволар хисабына хәл ителә торган чыгымнар»;

«- 09505 Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм итү фонды средстволары хисабына, Коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү буенча чараларны тәэмин итү» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 09505 Территорияләрне үстерү фонды средстволары хисабына, коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү буенча чараларны тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү буенча чараларны тәэмин итүгә «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга средстволарның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү буенча чараларны тәэмин итүгә «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясеннән Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына кире кайтарылмый торган керемнәр» 000 2 03 02080 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

«- 95010 Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлауга Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм итү фондыннан алынган средстволар хисабына хәл ителә торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 95010 Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлауга Территорияләрне үстерү фондыннан алынган средстволар хисабына хәл ителә торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлауга Территорияләрне үстерү фондыннан алынган средстволар хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Әлеге максатларга средстволарның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча чараларны тәэмин итүгә «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясеннән Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына кире кайтарылмый торган керемнәр» 000 2 03 02030 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.

Әлеге максатларга субсидияләрнең җирле бюджетларга керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Бюджетларга тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар» 000 2 02 49999 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.

Шулай ук чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Территорияләрне үстерү фонды средстволары хисабына хәл ителә торган, әлеге максатларга җирле бюджетларның чыгымнары чагылдырыла.».

2. 1нче кушымтада юлны

| | |
|---|---|
| «722 | Татарстан Республикасы Президентының Эшләр идарәсе» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «722 | Татарстан Республикасы Рәисенең Эшләр идарәсе». |

3. 2нче кушымтада:

а) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «02 4 03 96110 | Урта һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларын икътисадның реаль секторында эшләүче оешмалар белән интеграцияләү нигезендә оештырыла торган мәгариф-производство үзәкләрен (кластерлар) үстерүгә дәүләт ярдәме» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «02 4 03 R1770 | Алга китешле һөнәри әзерлек үзәкләрен булдыруга һәм аларның эшләвен тәэмин итүгә финанслашыла торган чыгымнар»; |

б) юлны

| | |
|---|---|
| «02 4 E6 51770 | Алга китешле һөнәри әзерлек үзәкләрен булдыруга һәм аларның эшләвен тәэмин итүгә финанслашыла торган чыгымнар» |

төшереп калдырырга;

в) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «03 1 01 66940 | Украина, Донецк халык республикасы, Луганск халык республикасы территорияләрендә даими яшәүче, Украина, Донецк халык республикасы, Луганск халык республикасы территорияләреннән китәргә мәҗбүр булып, ашыгыч һәм массакүләм тәртиптә Россия Федерациясе территориясенә килгән вакытлыча урнаштыру, тукландыру пунктларындагы Россия Федерациясе гражданнарын, чит ил гражданнарын һәм гражданлыксыз затларны урнаштыру һәм тукландыруга бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү (каплау)» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «03 1 01 94010 | «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе средстволары хисабына, даими яшәү урыныннан китәргә һәм ашыгыч һәм масскүләм тәртиптә даими яшәү урынына башка территорияләргә күченгән Херсон шәһәрендә һәм Херсон өлкәсенең бер өлешендә яшәгән кешеләргә мөлкәт сатып алуга бер тапкыр түләү бирү чыгымнары»; |

г) юлны

| | |
|---|---|
| «03 5 01 31440 | Сигез яшьтән унижиде яшькә кадәрге балага түләүне хәл итүгә Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетына субвенцияләр» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «03 5 01 31440 | Сигез яшьтән унижиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләүне хәл итүгә Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды бюджетына субвенцияләр»; |

д) юлны

| | |
|---|---|
| «03 5 01 31460 | Унҗиде яшькә кадәрге балалары булган аз керемле гаиләләргә һәм йөкле хатын-кызларга айлык универсаль пособие түләүгә финанслашыла торган чыгымнар |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «03 5 01 31460 | Бала тудыру һәм тәрбияләүгә бәйле айлык пособие түләүгә Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды бюджетына субвенцияләр»; |

е) юлны

| | |
|---|---|
| «04 4 F3 67483 | Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм итү фонды средстволары хисабына, «Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проектының «Яшәү өчен яраксыз торак фондын тотрыклы кыскартуны тәэмин итү» федераль проектын тормышка ашыру кысаларында 2019 – 2023 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча Республика адреслы программасы чараларын тәэмин итү» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «04 4 F3 67483 | Территорияләрне үстерү фонды средстволары хисабына, «Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проектының «Яшәү өчен яраксыз торак фондын тотрыклы кыскартуны тәэмин итү» федераль проектын тормышка ашыру кысаларында 2019 – 2023 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча Республика адреслы программасы чараларын тәэмин итү»; |

ж) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «04 К 00 00000 | «Татарстан Республикасында яшәүчеләрне сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» кече программасы» |

түбәндәге эчтәлектәге юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «04 К 00 03610 | «Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәге өчен инженерлык һәм юл инфраструктурасы объектларын төзү» объектын булдыру» |
| 04 К 00 03611 | «ВЭБ.РФ» үсеш дәүләт корпорациясе средстволары хисабына, «Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәге өчен инженерлык һәм юл инфраструктурасы объектларын төзү» объектын булдыру |
| 04 К 00 03612 | Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына, «Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәге өчен инженерлык һәм юл инфраструктурасы объектларын төзү» объектын булдыру»; |

з) юлны

| | |
|---|---|
| «04 К 00 72360 | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциясез оешмасына торак төзелеше буенча устав эшчәнлеген тормышка ашыруга субсидияләр» |

төшереп калдырырга;

и) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «09 2 G6 00000 | «Иделне савыктыру» федераль проекты |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «09 2 G6 19230 | Төбәк проекты нәтиҗәсенә ирешү өчен, Идел елгасына куркыныч белән янаучы әйләнә-тирә мохиткә тупланма зыян объектларын юкка чыгару (рекультивацияләү)»; |

к) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «13 6 01 03692 | Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына, Татарстан Республикасы Түбән Кама ш. «Акыллы машиналар» җаваплылыгы чикләнгән предприятиесенә килү өчен автомобилm юлы төзү» юл хуҗалыгы объектын булдыру» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

«13 6 01 07690 Дәүләти-хосусый партнерлык механизмын куллану нигезендә тормышка ашырылучы проектлар буенча юл эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү»;

л) юлдан соң

«14 1 06 63390 Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә яшелчә саклагычлар, җиләк-җимеш саклагычлар һәм бәрәңге саклагычлар төзү (реконструкцияләү) өчен проектлау эшләренә һәм проект-смета документларына дәүләт экспертизасы үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр»

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

«14 1 06 63410 Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә яшелчә саклагычлар, җиләк-җимеш саклагычлар һәм бәрәңге саклагычлар төзү (реконструкцияләү) буенча эшләр башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр»;

м) юлны

«26 0 J1 53320 Туристлык инфраструктурасын үстерүгә юнәлдерелгән җәмәгать башлангычларын тормышка ашыруга ярдәм итүне тәэмин итүгә финанслашыла торган чыгымнар»

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26 0 J1 53320 Туристлык инфраструктурасын үстерүгә юнәлдерелгән җәмәгать башлангычларын тормышка ашыруга ярдәм итүне тәэмин итү»;

н) юлны

«26 0 J2 53300 Вакыйгаи чараларга ярдәм итү һәм этәргеч бирү программасын булдыру һәм гамәлгә кертүгә финанслашыла торган чыгымнар»

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26 0 J2 53300 Вакыйгаи чараларга ярдәм итү һәм этәргеч бирү программасын булдыру һәм гамәлгә кертү»;

о) юлдан соң

«26 К J1 00000 «Туристлык инфраструктурасын үстерү» федераль проекты»

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

«26 К J1 53330 Шәһәр үзәгенең туристлык кодын проектлау буенча төбәк программаларына дәүләт ярдәме»;

п) юлны

«37 1 P5 52290 Спортка әзерләү оешмаларын нормативта каралган халәткә туры китерү өчен спорт җиһазларын һәм кирәк-ярагын сатып алуга финанслашыла торган чыгымнар»

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«37 1 P5 52290 Үз атамасында «олимпия» яки шуның нигезендә ясалган сүздән яки сүзтезмәдән файдаланучы, «спорт мәктәбе» дигән махсус атамалы өстәмә белем бирү лешмаларын нормативта каралган халәткә китерү өчен спорт җиһазларын һәм кирәк-ярагын сатып алуга финанслашыла торган чыгымнар»;

р) юлны

«51 0 00 00000 Татарстан Республикасы Президентының Эшләр идарәсен тотуга чыгымнар»

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«51 0 00 00000 Татарстан Республикасы Рәисенең Эшләр идарәсен тотуга чыгымнар» Ра

с) юлдан соң

«99 0 00 93990 Хуҗалык хезмәте күрсәтүне тәэмин итү буенча учреждениеләр»

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

«99 0 00 94020 Даими яшәү урыныннан китәргә мәҗбүр булган һәм ашыгыч тәртиптә күпләп даими яшәү урынына башка территорияләргә күченгән Херсон шәһәрендә һәм Херсон өлкәсенең бер өлешендә яшәгән кешеләргә гражданинның социаль түләүгә хокукын раслаучы дәүләт торак сертификатлары нигезендә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү өчен Территорияләрне үстерү фондыннан алынган средстволар хисабына хәл ителә торган чыгымнар»;

т) юлны

«99 0 00 09500 Коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү проектын тормышка ашыруга Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм итү фондыннан алынган средстволар хисабына хәл ителә торган чыгымнар»

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«99 0 00 09500 Коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү проектын тормышка ашыруга Территорияләрне үстерү фондыннан алынган средстволар хисабына хәл ителә торган чыгымнар»;

у) юлны

«99 0 00 09505 Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм итү фонды средстволары хисабына коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләүбуенча чараларны тәэмин итү»

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«99 0 00 09505 Территорияләрне үстерү фонды средстволары хисабына коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләүбуенча чараларны тәэмин итү»;

ф) юлны

| | |
|---|---|
| «99 0 00 95010 | Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлауга Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм итү фондыннан алынган средстволар хисабына хәл ителә торган чыгымнар» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «99 0 00 95010 | Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлауга Территорияләрне үстерү фондыннан алынган средстволар хисабына хәл ителә торган чыгымнар». |